| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>Менделеевский муниципальный район<br>Совет Мунайкинского сельского поселения | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>Менделеевск муниципаль районы<br>Монай авыл жирлеге Советы |

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

2021 нче елның 17 нче ноябрендәге 47 нче нмерлы КАРАРЫ

“Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль
районы Монай авыл җирлегендә бюджет процессы
турында " гы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлеге Советы
Карар кылды:

1. 2020 нче елның 31 нче январендәге 159 нчы номерлы Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлеге Советы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлегендә бюджет процессы турында”гы нигезләмәгә үзгәрешләр кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 15 статьясындагы 12 пунктының 2 пунктачысын түбәндәге редакциядә өстәргә:

- 2) җирлек бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының бюджетка керүенең тулылыгын һәм үз вакытында керүен, бюджетның бердәм счетындагы калдыклар белән идарә итү операцияләреннән тыш , тикшереп торуны гамәлгә ашыра;;

1.2. Нигезләмәнең 35 статьясындагы 27 пунктына түбәндәге эчтәлекле тәкъдим өстәргә: "кредит (займ) буенча принципал йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итүче муниципаль гарантия кредит килешүендә (займ килешүендә) һәм (яисә) күрсәтелгән муниципаль гарантияне бирү турындагы шартнамәдә кредитор (заемчы) йөкләмәләрен үз ягыннан күрсәтелгән кредит (займ) акчаларының максатчан кулланылышын тикшереп тору шарты белән бирелә.";

1.3. Нигезләмәнең 13 статьясындагы 3 пунктының 5 пунктчасына "Россия Федерациясе законнарында каралган очраклардан тыш"сүзләрен өстәргә;

1.4. Нигезләмәнең 13 статьясындагы 2 пунктының 4 пунктчасын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

4) Россия Федерациясе керемнәре чыганаклары исемлегенә һәм бюджет керемнәре чыганаклары реестрына кертү өчен аларга беркетелгән керемнәр чыганаклары турында белешмәләр тапшыра;";

1.5. Нигезләмәнең 41 статьясындагы 1 өлеше:

түбәндәге эчтәлекле өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

1)Россия Федерациясенең милли үсеш максатларын һәм аларга ирешү буенча гавами хакимият органнары эшчәнлегенең юнәлешләрен билгели торган документлар турында;;

2) өченче – дүртенче абзацларны дүртенче - бишенче абзацлар дип санарга;

2. Әлеге карарны Монай авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмати стендларда урнаштырып таныштырырга, Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында . https://mendeleevsk.tatar.ru Монай авыл җирлеге " бүлегендә, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында https://pravo.tatarstan.ru урнаштырырга

3. Әлеге карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Монай авыл җирлеге Советы рәисе Р.М.Кириллов